**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2025 елның 21 гыйнварындагы 71 номерлы карары**

**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2023 елның 26 апрелендәге 1189 номерлы**
**«Муниципаль милектә булган җир кишәрлеген, сатулар үткәрмичә, милеккә, арендага, даими (вакыты чикләнмәгән) файдалануга, бушлай файдалануга бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында»гы карарына үзгәреш кертү хакында**

2024 елның 8 августындагы 319-ФЗ номерлы «Россия Федерациясе Җир кодексына һәм “Авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләр әйләнеше турында”гы федераль законның 10 һәм 10.1 статьяларына үзгәрешләр кертү турында»гы федераль закон белән Россия Федерациясе Җир кодексының 39.16 статьясына үзгәрешләр кертелүгә бәйле рәвештә **карар бирәм**:

1. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2023 елның 26 апрелендәге 1189 номерлы карары (аңа Казан шәһәре Башкарма комитетының 2024 елның 1 апрелендәге 1242 номерлы, 2024 елның 14 маендагы 2005 номерлы, 2024 елның 30 сентябрендәге 4087 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган Муниципаль милектә булган җир кишәрлеген, сатулар үткәрмичә, милеккә, арендага, даими (вакыты чикләнмәгән) файдалануга, бушлай файдалануга бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентының 2.8.2.1. пунктына, 13 пунктчасында «яисә крестьян (фермер) хуҗалыгы тарафыннан үз эшчәнлеген гамәлгә ашыру» сүзләрен төшереп калдырып, үзгәреш кертергә.

2. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырып чыгарырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары Р.Р.Шәфигуллинга йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**